# КАРАР

Азнакай шәһәре №211-31 «12» ноябрь 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының
2012 елның 28 апрелендәге «Өч һәм аннан да
күбрәк балалары булган гражданнарга җир кишәрлекләре
бирү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында» 139-20
номерлы карары (22.10.2013 ел, № 274-37, 2017 елның 9
ноябрендәге 147-22 номерлы карарлар редакциясендә) белән
расланган «Өч һәм аннан да күбрәк балалары булган
гражданнарга җир кишәрлекләре бирү турында» карарлар
кабул итү тәртибенә үзгәреш кертү турында)

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының муниципаль милкендәге мөлкәт һәм җир кишәрлекләре милекчесе вәкаләтләрен 2018 елның 1 октябреннән «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы» муниципаль казна учреждениесенә тапшыруны исәпкә алып һәм «Ихтыяҗ критерийларын куллану принцибын үтәү бурычыннан чыгып, социаль ярдәм чараларын бирүне исәпкә алу һәм камилләштерү» өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында 29.12.2015 ел, № 388-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай район Советы **карар чыгарды:**

1. «Өч һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү» турында карарлар кабул итү тәртибе хакында 139-20 номерлы карары (2013 елның 22 октябрендәге 274-37 номерлы, 2017 елның 9 ноябрендәге 147-22 номерлы карарлар редакциясендә) белән расланган «Өч һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү» турында карарлар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 15 пунктта түбәндәге эчтәлекле 8 пунктчаны өстәргә::
«8) индивидуаль счетның иминият номеры (СНИЛС)».
1.2. 20 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Вәкаләтле орган кергән документлар белән гаризаны карый, мөрәҗәгать итүчене җир кишәрлеген алу хокукына ия гражданнар исемлегенә кертү турында Карар кабул итә».
1.3.21 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«21. Гаризада күрсәтелергә тиешле мәгълүматлар булмаганда яисә тулы булмаган очракта, шулай ук мөрәҗәгать итүче гаризаны теркәгәннән соң утыз көн эчендә әлеге Тәртипнең 15 пунктында каралган документларны тапшырмаса, йә мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар мөрәҗәгать итүченең индивидуаль торак төзелешен, дача төзелешен,шәхси ярдәмче хуҗалыкалып бару, яшелчәлек, бакчачылык алып бару өчен бушлай җир участогы алу хокукын расламаган очракта, җирле үзидарәнең вәкаләтле органы мөрәҗәгать итүчене исемлекләргә кертүдән баш тарту турында Карар кабул итә. Гаризага "кире кагылган"статусы бирелә.
1.4.23 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«23. Гражданнарны җир кишәрлекләре белән тәэмин итү максатыннан Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты түбәндәге чаралар үткәрүне тәэмин итә:

- шәхси торак төзелеше, дача төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару (йорт яны җир участогы), бакчачылык яки яшелчәчелек өчен җир кишәрлекләренең урнашу урыннарын билгеләү;
-объектларны инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыруның техник шартларын, транспорт үтемлелеген һ.б. билгеләү.
Вәкаләтле орган түбәндәге чараларны үткәрүне тәэмин итә
- җир кишәрлекләрен формалаштыру турында Карар кабул итү;
- җир кишәрлекләрен кадастр исәбенә кую;
- мәгълүмат материалларын әзерләү, аларны муниципаль берәмлек сайтында урнаштыру».
1.5.25 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«25. Җир кишәрлеген сайлау процедурасын үткәрү өчен комиссия төзелә. Комиссия составы һәм аның эш тәртибе вәкаләтле органның хокукый акты белән билгеләнә.
1.1. 27 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«27. Җир кишәрлеген бирү турындагы карар әлеге Тәртипнең 26 пунктында күрсәтелгән акт нигезендә аны имзалау датасыннан ундүрт көннән дә соңга калмыйча вәкаләтле орган тарафыннан кабул ителә. Гаризага "Участок бирелгән" статусы бирелә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru. һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин